ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.01.2021 М ө с л и м № 14

**2021 һәм 2022 елга Мөслим районы халкын ВИЧ-инфекцияне ачыклау өчен медицина тикшерүе белән колачлауны киңәйтү буенча чаралар планын («Юл картасы») һәм ВИЧ-инфекция таралуга каршы тору буенча беренчел чаралар планын раслау турында**

Район халкының кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) белән авыруын киметү, район халкын һәм зарарланырга мөмкин төп төркемнәрдә профилактик эшне көчәйтү, үткәрелә торган чаралар комплексының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары тарафыннан максатчан күрсәткечләрнең үтәлешен тикшерүне оештыру өчен расланган «2021-2022 елларда Татарстан Республикасында ВИЧ-инфекцияне таратуга каршы тору буенча беренчел чаралар планы»н үтәү йөзеннән түбәндәгеләрне **РАСЛАРГА**:

1. - 2021-2022 елларда Мөслим муниципаль районында ВИЧ-инфекция таралуга каршы тору буенча беренчел чаралар планы (1 нче кушымта).

- Мөслим муниципаль районы халкының, шул исәптән халыкның зарарланырга мөмкин төп төркемнәренең ВИЧ-инфекциясен ачыклау өчен медицина тикшерүен колачлауны киңәйтү һәм аның нәтиҗәлелеген 2022 елга кадәр күтәрү чаралары планы («Юл картасы») (2 нче кушымта).

- Мөслим муниципаль районында ВИЧ-инфекциягә каршы профилактика һәм көрәш буенча ведомствоара комиссия чаралары планы (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында http://muslumovo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М. Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Р.А. Ильясов**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» __гыйнвар 2021 елнын,
__14___номерлы карарына
1 нче кушымта

**2021-2022 елларда Мөслим муниципаль районында ВИЧ-инфекция таралуга каршы тору буенча беренчел чаралар планы**

| № | Чаралар атамасы | Башкару вакыты | Көтелгән нәтиҗә | Чараны гамәлгә ашыруның максатчан күрсәткечләре | Үлчәү берәмлекләре | Максатчан күрсәткечләр: | | | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Фактта | План буенча | План буенча | |
| | | | | | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| **Ресурсларга булган ихтыяҗны бәяләү һәм өстенлекләрне билгеләү** | | | | | | | | | |
| 1. | Тиешле ведомствоара программаларны гамәлгә ашыру максатларында ВИЧ-инфекцияне таратуга каршы тору буенча ведомствоара комиссия эшен оештыру | Ел дәвамында | Мөслим муниципаль районында ВИЧ-инфекция таралуга каршы чараларны гамәлгә ашыру кысаларында барлык кызыксынучы хезмәтләр һәм | ВИЧ-инфекция таралуга каршы тору буенча ведомствоара комиссиянең эш планын раслау | Субъект актының исеме, №, датасы | әйе | әйе | Агымдагы елның декабрь ахырына кадәр ведомствоара килешү | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы ведомствоара комиссия |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ведомстволарның үзара хезмәттәшлеген киңәйтү | | | | | | |
| | | | | ВИЧ-инфекциянең таралуына каршы тору буенча үткәрелгән утырышлар саны | берәмлек | 3 | 4 | | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы ведомствоара комиссия |
| | | | | ВИЧ-инфекция таралуга каршы көрәш буенча ведомствоара комиссиянең төрле хезмәтләр һәм ведомстволар белән килештерелгән карарлары саны | берәмлек | 3 | 4 | | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы ведомствоара комиссия |
| 2. | ВИЧ-инфекция буенча эпидемиологик вәзгыятькә (социаль, җенес-яшь һ.б.) һәм ВИЧ - инфекция тапшыру юлларына анализ ясау | Ел саен | Мөслим муниципаль районында ВИЧ-инфекция таралуга каршы чараларны планлаштырганда максатларны оптимальләштерү һәм ресурслардан рациональ файдалану | Башкарма хакимият органнары тарафыннан расланган ВИЧ–инфекцияне таратуга каршы тору чараларын гамәлгә ашыру буенча ведомствоара планнар булу | наличие | әйе | әйе | | «Мөслим ҮРХ» ДАССО, Татарстан Республикасы буенча Минзәлә, Актаныш, Мөслим, Тукай районнарында, Яр Чаллы шәһәрендә Роспотребнадзор идарәсе. |
| **ВИЧ-инфекцияне профилактикалауга һәм иртә ачыклауга юнәлдерелгән чаралар комплексы** | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | ВИЧ-инфекция һәм аның белән ассоциацияләнгән авырулар мәсьәләләре буенча мәгълүмати агарту компаниясен гамәлгә ашыру | Ел саен | ВИЧ-инфекция һәм аның белән ассоциацияләнгән авырулар мәсьәләләре буенча халыкның хәбәрдарлык дәрәҗәсен күтәрү, кеше иммунодефициты вирусына карата үз-үзеңне тотышның куркыныч тәртибен үзгәртү | ВИЧ–инфекция һәм аның белән ассоциацияләнгән авырулар мәсьәләләре буенча, шулай ук гамәлгә ашырылган мәгълүмати - агарту компаниясе турында халыкка мәгълүмат бирү дәрәҗәсе | процент | 90% | 90% | | Мөслим муниципаль районы «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 4 | Белем бирү оешмаларында видеофильмнар күрсәтеп, агарту әдәбиятын таратып лекцияләр үткәрү | Ел саен | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында ВИЧ-инфекция мәсьәләләре буенча халыкның белем дәрәҗәсен күтәрү; кеше иммунодефициты вирусына карата карата үз-үзеңне тотышның куркыныч тәртибен үзгәртү; 15-25 яшьлекләр | Мөслим районы мәгариф оешмаларының гомуми саныннан ВИЧ-инфекция белән көрәш буенча акция үткәрүгә җәлеп ителгән мәгариф учреждениеләрен ең өлеше | процент | кимендә 90 % | кимендә 90 % | | «Мөслим муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ, «Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | арасында ВИЧ-инфекциянең яңа очраклары санын киметү; кеше иммунодефициты вирусы йоктырган балалар һәм яшүсмерләргә карата стигманы киметү һәм дискриминациягә юл куймау | | | | | | |
| | | | | Беренче тапкыр ачыкланган ВИЧ-инфекциянең барлык очракларыннан 15-25 яшьлек яшьләр арасында ВИЧ-инфекция очракларының өлеше | процент | 10 % тан артык түгел | 10 % тан артык түгел | | Мөслим муниципаль районы «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 5 | Хастаханәдә ВИЧ-инфекция йоктыруны һәм һөнәр ияләрнең зарараланyуын профилактикалау чараларын уздыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү | Ел саен | Медицина хезмәткәрләренең 100% ы да ВИЧ-инфекцияне профилактикалау мәсьәләләре буенча белем дәрәҗәсен күтәрүе | Хастаханәдә ВИЧ-инфекция йоктыру очраклары булмау | әйе / юк | юк | юк | | Мөслим муниципаль районы «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| | | | | ТР Мөслим муниципаль районында ВИЧ- | әйе / юк | юк | юк | | Мөслим муниципаль районы «Мөслим |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | инфекция белән профессиональ йогышлану очракларының булмавы | | | | | ҮРХ» ДАССУ |
| **Медицина тикшерүе үткәрүне киңәйтүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы** | | | | | | | | | |
| 6 | ВИЧ-инфекцияне, шул исәптән инфекцияләнгән йөкле хатын-кызларны ачыклау буенча сәламәтлек саклауның беренчел звеносы медицина оешмалары эшенең нәтиҗәлелеген арттыру | Ел саен | Үз статусы турында хәбәр ителгән затларның өлешен арттыру | Мөслим муниципаль районында ВИЧ-инфекциягә тикшеренү узган затлар саны | кеше | 1796 | | | Мөслим муниципаль районы «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| | | | Беренче тапкыр ачыкланган ВИЧ-инфекция булган затлар арасында СД4 күләме 350 күзәнәк/мл дан да ким булган сандагы затларның өлешен кимендә 30% ка арттыру, йөклелек буенча хатын-кызлар консультацияләренә исәпкә куелганда хатын-кызларда | Халык арасында ВИЧ-инфекциягә тикшерү үткән затлар өлеше | процент | кимендә 9.4% | кимендә 23% | | Мөслим муниципаль районы «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ВИЧ-инфекцияне вакытында ачыклау | | | | | | |
| 7 | | | | Беренче тапкыр ачыкланган ВИЧ-инфекцияле затлар саны | кеше | 1 | | | Мөслим муниципаль районы «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| | | | | Беренче тапкыр ачыкланган ВИЧ-инфекция булган затлар арасында СД4 күләме 350 күзәнәк/мл дан да ким булган сандагы затларның өлеше | процент | 1,6% тан артык түгел | 30% тан артык түгел | | |
| | | | | | | | | | |
| **Халыкның зарарланырга мөмкин төркемнәрендә ВИЧ-инфекцияне профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар комплексы, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар катнашында** | | | | | | | | | |
| 7 | Хезмәт коллективларында ВИЧ-инфекцияне профилактикалау мәсьәләләре буенча лекцияләр оештыру | Ел саен | Мөслим муниципаль районы хезмәт коллективларында ВИЧ-инфекция мәсьәләләре буенча белем дәрәҗәсен ел саен кимендә 30% ка арттыру | Хезмәт коллективларында ВИЧ-инфекция мәсьәләләре буенча санитар-агарту чаралары белән колачланган хезмәткәрләр саны | кеше | 440 | 220 | | «Мөслим ҮРХ» ДАССО, Татарстан Республикасы буенча Минзәлә, Актаныш, Мөслим, Тукай районнарында, Яр Чаллы шәһәрендә Роспотребнадзор идарәсе |
| 8 | Эш урынында ВИЧ-инфекциягә тест үткәрүне | | | Хезмәт коллективларында ВИЧ- | кеше | 0 | 0 | | «Мөслим ҮРХ» ДАССО, Татарстан |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | оештыру | | | инфекциягә тест үткәрү белән тәэмин ителгән хезмәткәрләр саны | | | | | Республикасы буенча Минзәлә, Актаныш, Мөслим, Тукай районнарында, Яр Чаллы шәһәрендә Роспотребнадзор идарәсе. |

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» __гыйнвар 2021 елның,
__14___номерлы карарына
2 нче кушымта

**Мөслим муниципаль районы халкының, шул исәптән халыкның зарарланырга мөмкин төркемнәренең ВИЧ-инфекциясен ачыклау өчен медицина тикшерүен колачлауны киңәйтү һәм аның нәтиҗәлелеген 2022 елга кадәр күтәрү чаралары планы («Юл картасы»)**

***1. «Юл картасы»ның гомуми тасвирламасы***

Мөслим муниципаль районы халкының, шул исәптән халыкның зарарланырга мөмкин төркемнәренең ВИЧ-инфекциясен ачыклау өчен медицина тикшерүен колачлауны киңәйтү һәм аның нәтиҗәлелеген 2022 елга кадәр күтәрү чаралары планы («Юл картасы») халыкның ВИЧ-инфекциягә медицина тикшерүе уздыруны арттыру механизмнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән. Лаборатория тикшерүе һәм консультацияләүне үз эченә алган ВИЧ-инфекциясенә медицина тикшерүе авыруны иртә ачыклауны һәм вакытында дәвалауны тәэмин итәргә, шулай ук ВИЧ-инфекция диагнозы куелган пациентлар белән индивидуаль эш ярдәмендә ВИЧ-инфекция белән зарарлануның яңа очракларын булдырмый калырга мөмкинлек бирә.

***«Юл картасы» ның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:***

- ресурсларга булган ихтыяҗны бәяләү һәм өстенлекләрне билгеләү;
- халыкта ВИЧ-инфекциясенә медицина тикшерүен даими узуга мотивация формалаштыру;
- ВИЧ-инфекцияне иртә ачыклау һәм диагностикалау мәсьәләләре буенча медицина кадрларын әзерләү;
- Республика медицина оешмаларының, шул исәптән беренчел медик – санитар ярдәм күрсәтүчеләрнең ВИЧ-инфекцияне ачыклау буенча эш нәтиҗәлелеген арттыру;
- халыкның зарарланырга мөмкин төркемнәрендә ВИЧ-инфекциясен ачыклау өчен, күчмә эш рәвешләрен оештыруны да кертеп, медицина тикшеренүе белән колачлауны арттыру, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар катнашында да.

## 2. *«Юл картасы»ның контроль күрсәткечләре*

| Контроль күрсәткеченең исеме | Үлчәү берәмлеге | 2020 | 2021 | 2022 |
|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының ВИЧ-инфекциясенә халыкны медицина тикшерүе белән тәэмин итүне арттыру буенча чараларны регламентлаштыручы боерыгы булу | булу (әйе/юк) | әйе | әйе | - |
| ВИЧ-инфекция һәм аның белән бәйле авырулар, шулай ук гамәлгә ашырылган информатив - агарту кампаниясе мәсьәләләре буенча халыкның хәбәрдарлык дәрәҗәсе | процент | 90% | 90% | - |
| Мөслим муниципаль районы халкыннан ВИЧ-инфекциягә тикшерелгән затлар өлеше | процент | 9,4% | 25% | - |
| ВИЧ-инфекциягә тикшерү узган халыкның зарарланырга мөмкин төркемнәреннән булган затлар саны | кеше | 92 | | - |

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» __гыйнвар 2021 елнын,
__14___номерлы карарына
3 нче кушымта

### *3. Чаралар планы*

| № | Чаралар атамасы | Башкару вакыты | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| Ресурсларның өстенлекләрен билгеләү һәм ихтыяҗларын бәяләү | | | |
| 1 | ВИЧ-инфекциянең таралуын кисәтү, кеше иммунодефициты вирусы белән зарарланган затларга, ВИЧ-инфекцияле аналар тудырган балаларга социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен, шулай ук ВИЧ-инфекция таралуга эпидемиологик контроль (күзәтчелек) мәсьәләләрен регламентлаучы норматив хокукый актларны актуальләштерү | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 2 | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия утырышларында халыкны ВИЧ-инфекциягә тикшерүне оештыру һәм аның нәтиҗәлелеге турындагы мәсьәләләрне тыңлау. Халыкның даими рәвештә ВИЧ-инфекциягә медицина тикшерүен узуга мотивация формалаштыру | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 3 | Мәгълүмати – агарту кампанияләре кысаларында ирекле һәм конфиденциаль тест үткәрү юлы белән ВИЧ–инфекцияне иртә ачыклау мөһимлеге мәсьәләләрен, шулай ук ВИЧ–инфекцияне профилактикалау буенча чараларны яктырту, хезмәт коллективларында һәм халыкның башка төркемнәрендә яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвеше культурасын формалаштыру | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 4 | ВИЧ-инфекцияне профилактикалау мәсьәләләре буенча, шул исәптән | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ВИЧ-инфекциягә тикшерү кирәклеге турында мәгълүматны да кертеп, халык арасында мәгълүмати материаллар тарату | | |
| 5 | Халык өчен ВИЧ-инфекциягә тикшерү узу кирәклеген яктыртучы профилактик акцияләр үткәрү | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 6 | ВИЧ-инфекцияне иртә ачыклау һәм диагностикалау мәсьәләләре буенча медицина кадрларын әзерләү | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 7 | ВИЧ-инфекцияне иртә диагностикалау мәсьәләләре, ВИЧ-инфекциягә медицина тикшерүен уздыру кагыйдәләре, шул исәптән алдан һәм аннан соң тест консультациясе турында табиблар һәм урта медицина хезмәткәрләре өчен укыту семинарларын оештыру һәм уздыру. | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 8 | Мөслим муниципаль районы медицина оешмаларының, шул исәптән беренчел медик – санитар ярдәм күрсәтүче медицина оешмаларының ВИЧ-инфекцияне ачыклау буенча эш нәтиҗәлелеген арттыру | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 9 | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы медицина оешмаларында В, С вируслы гепатитларга һәм ВИЧ-инфекцияләренә скрининг оештыру турында» 2017 елның 4 сентябрендәге 1838 номерлы боерыгы белән расланганнан да ким булмаган күләмдә, күбесенчә халыкның зарарланырга мөмкин төркемнәреннән булган затлар исәбенә (халыкның югары хәвеф-хәтәр төрләре, зәгыйфь һәм халыкның аеруча зәгыйфь төркемнәре) ВИЧ-инфекциягә тикшерү үткәрүне тәэмин итү. | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 10 | Теләсә кайсы медицина ярдәме белән медицина оешмаларына мөрәҗәгать иткәндә ВИЧ-инфекция медицина тикшерүе үтү мөмкинлеге турында гражданнарга актив хәбәр итү | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 11 | Йөкле хатын – кызларда һәм бала табучыларда ВИЧ-инфекцияне вакытында ачыклау максаты белән ВИЧ-инфекцияне диагностикалау өчен экспресс-тестлар запасын тәэмин итү | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 12 | Халыкның зарарланырга мөмкин төркемнәрендә ВИЧ-инфекцияне ачыклау өчен, күчмә эш рәвешләрен оештыруны да кертеп, медицина тикшеренүе белән колачлауны арттыру, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар катнашында да | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13 | «ТР сәламәтлек саклау учреждениеләренә хокук саклау органнары тарафыннан медицина тикшерүенә китерелгән затларны ВИЧ-инфекциягә тикшерүне оештыру турында» ТР ССМ 2013 елның 19 февралендәге 244 номерлы боерыгы нигезендә, хокук саклау органнары тарафыннан медицина тикшерүенә китерелгән затларны һәм медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итүче барлык наркотик кулланучыларны ВИЧ-инфекциягә максималь рәвештә тест үткәрүне тәэмин итәргә | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 14 | Ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында җәза үтүче һәм сак астына алынган затлар өчен ВИЧ-инфекциясе проблемасы буенча мәгълүмати-агарту эш үткәрү белән берлектә ВИЧ-инфекциясенә ирекле медицина тикшерүе үткәрү | ел саен | «Мөслим ҮРХ» ДАССУ |
| 15 | Мөслим муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә профилактик акцияләр оештыру | ел саен | «Мөслим РҮХ» ДАССУ |
| 16 | ВИЧ-инфекцияле авыручылар белән контактта булган затларның билгеләнгән срокларында ВИЧ-инфекциягә медицина тикшерүен дә кертеп, диспансер күзәтүен оештыру һәм үткәрү | ел саен | «Мөслим РҮХ» ДАССУ |